КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 июнь г.Казань № 378

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендә булган һәм хуҗалык алып бару хокукында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасының дәүләт учреждение-ләренә беркетелгән күчемсез мөлкәтне алуны килештерү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 6 июль, 497 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган һәм хуҗалык алып бару хокукында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасының дәүләт учреждение-ләренә беркетелгән күчемсез мөлкәтне алуны килештерү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендә булган һәм хуҗалык алып бару хокукында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләренә беркетелгән күчемсез мөлкәтне алуны килештерү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 6 июль, 497 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган һәм хуҗалык алып бару хокукында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләренә беркетелгән күчемсез мөлкәтне алуны килештерү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2017 елның 1 гыйнварына кадәр бирелгән техник паспорт күчермәсе яисә кадастр паспорты яки «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» Федераль закон көченә кергәнче билгеләнгән тәртиптә бирелгән, күчемсез милек объектлары тасвирламасын үз эченә алган бүтән документлар;»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Мөлкәтне алуны килештергәндә оешма Җир һәм мөлкәт министрлыгына түбәндәгеләрне тапшырырга хокуклы:

Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – Реестр) мөлкәт (бина, төзелмә, корылма) турында мәгълүматларны үз эченә алган өземтә яки соратылган мәгълүматларның Реестрда булмавы турында белдерү кәгазе;

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе.

Оешма әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта Җир һәм мөлкәт министрлыгы аларны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә соратып ала.».

2. Әлеге карарның көче 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\378.docx